| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

«14» март 2022 ел Олы Кайбыч ав. № 106

**2021 елда Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлекчәсе оператив-хезмәт эшчәнлеге йомгаклары турында**

Кайбыч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы бүлекчәсе башлыгы, полиция подполковнигы Р.Г.Хуҗинның «Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлегенең 2021 елда оператив-хезмәт эшчәнлеге йомгаклары турында» чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң, Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлекчәсе эшен канәгатьләнерлек дип бәяләргә. Мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлекчәсе башлыгына (Р.Г.Хуҗинга) бүлекчә эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә өстәмә чаралар күрүне тәкъдим итәргә, төп көчләрне түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- коррупциягә каршы көрәш чараларының нәтиҗәлелеген күтәрү;
- икътисадый юнәлештәге җинаятьләрне ачыклау һәм ачу;
-алкоголь һәм спиртлы продукцияне законсыз сатуга бәйле җинаятьләрне ачыклау һәм ачу;
- корал һәм наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәшнең нәтиҗәлелеген күтәрү;
-террорчылыкның һәм экстремизмның төрле рәвешләренә каршы тору эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү;
-мәгълүмати-телекоммуникация технологияләрен кулланып кылынган җинаятьләрне ачу һәм тикшерү буенча профилактик чараларның нәтиҗәлелеген арттыру.

3. Даими нигездә үз-үзен деструктив тотышка һәм хокук бозуларны кылуга тартым балигъ булмаганнар турында белем бирү учреждениеләре белән

үзара мәгълүмат алмашуны билгеләргә, төркем җинаятьләре, балигъ булмаганнар тупланмалары, административ хокук бозулар белән бәйле хәлләр турындагы хәбәрләргә тиешле җавап бирүне тикшереп торырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин